Управление культуры и организации досуга населения
администрации города Ульяновска
Муниципальное бюджетное учреждение культуры
«Централизованная библиотечная система»

# Татар халкының иң кадерле милли бәйрәме

(Самый дорогой и национальный праздник татарского народа)

*Методический материал, посвященный Сабантую.*



Ульяновск 2016

## *Сабантуй*

Яланнарда сабантуйлар гөрли,
Яшь егетләр сыза гармунын,
Уйнаклатып җилләр алып китә
Еракларга гармуннар моңын.
Вак-вак атлап биегән кызлар ялгыш
Йөрәгеңә басар кебекләр.
Җаен табып кына сылуларга
Каш сикертеп уза егетләр
Бәйгеләрдә - җилдән җитез атлар,
Дагалардан очкын чәчелә.
Ат өстендә килгән үсмерләрнең
Ут кабыныр сыман чәченә.
Яланнарда сабантуйлар гөрли,
Бәхетлесе илнең бүген мин.
Хәтфә кебек яшел яланнарга
Ачып салган халкым күңелен...

(Харрас Әюп)



Сабантуй Фаттахов Л.А.

Менә тагын алдыбызда кырлары вә болыннары төрле төстәге чәчәкләргә күмелгән июнь ае тора. Әйтерсең, бу айга хак Тәгәлә дөньяның бөтен матурлыгын җыеп биргән. Хәер, бу айны безнең халык үзенең җирле календареннда “җәй ае”, “чәчәк ае” дип тә йөрткән. Җирле халык телендә ул “сабан ае” дип тә йөртелгән. Хәер, июнь башларында инде кыр эшләре тәгәлләнә диярлек. Менә шул вакытларда халык, тирә-күрше авыллар белән үзара киңәшеп, кемгә, кайчан Сабан туен уздыру көнен билгели. Сабан туе – ул бик борынгы заманнардан килә торган милли бәйрәм. Сабан туена шәһәр җирләреннән, башка төбәкләрдә яшәгән туган-тумача, кардәш-ыру, дус-ишләр, таныш-белешләр бергә кунакка җыйналар.

Элеккеге заманнарда Сабантуйны кар киткәч тә, язгы сукага төшәр алдыннан үткәрә торганнар иде, -дип сөйлиләр.

Язгы чәчүләр тәгәлләнгәч, кыр эшләреннән бушагач, Сабан туенда халык әзрәк көч сынашып, күңел ачып ала. Бу бәйрәм көннәрендә авылдан авылга йөреп күңел ачулар атналар буена сузыла. Бу бәйрәмнең башка бәйрәмнәргә охшаш ягы юк.

Бәйрәм алдыннан солдатка алынасы авыл яшьләре гармуннар белән озын-озын колгалар күтәреп авыл әйләнә. Яшь киленнәр колга башына оч-очлары чиккән сөлгеләр, күзнең явын алырдай итеп эшләнгән ашъяулыклар бәйлиләр. Ул сөлге, ашъяулыкларны яшь кызлар кышкы кичләрдә махсус Сабан туе өчен чигәләр.

Ниһаять, алдан билгеләнгән Сабан туе көне дә килеп җитә. Монда

инде башка елларны чабышларда катнашкан атлар да, көрәшләрдә күп мәртәбәләр дан тоткан баһадирлар да, җыр-бию, нәфис сүз осталары да, төрле мәзәкчеләр дә үзләренең киемнәре; төс-кыяфәтләре белән башкалардан аерылып торалар. Монда бөтен кеше дә катнаша. Халык тамашачы да, төрле рәвештә тамашалар кылучы да. Ул шул төре белән башка бәйрәмнәрдән аерыла да.

Монда нинди генә тамашалар юк: бәйрәмнең күрке булган атлар узышы, көрәшчеләр, йөгерүчеләр, күз бәйләп чүлмәк ватучылар, багана башыннан бүләк алучылар, капчык киеп йөгерүчеләр, гер күтәрүчеләр, агач аякта йөрүчеләр, кузла өстендә капчык белән сугышучылар. Башын тыгып катык эченнән көмеш акча эзләүчеләр, көянтә-чиләк белән су ташучылар, аркан тартучылар. Монда нинди генә уеннар юк. Бу уеннар һәркайсы да үзара дуслыкны ныгыта, кардәшлек тойгыларын уята, катлаулы тормыш ыгы-зыгысы белән зәгыйфьләнгән туганлык тамырларына дәва бирә.

Календарьда күрсәтелгәнчә, бу айда әле астрономик җәй дә башлана. Ул, гадәттәгечә, 22 нче июньннән, җәйге кояш торгынлыгыннан исәпләнә. Анысы инде – көннең озынлыгы иң соңгы чиккә барып җиткән. Бу вакытта кичке шәфәкъ батырга өлгерми, таң да ата башлый.

Сабантуйның дәртләндерә, шаукым бирә торган өлеше, әлбәттә, ат ярышы. Кайчандыр, бик күп заманнар элек көчле, зифа, сылу кыяфәтле елкыны кеше үзенә дус, иптәш ясый. Ихтимал, елкының инстинкты да бөтен ерткычлардан көчлерәк булган адәм баласы канаты астына тыкшынуның яхшырак, уңайрак булуын тойгандыр. Ир-егет үз гомерен ат белән бәйләгән, елкыны үзенә ияләштергәннән соң, алар бер организм кебек яшәгәннәр. Юманнарның уйма сәнгатендә ир белән ат бер бөтен организм итеп ясалган. Безнең халыкта тулпар диләр андый атны. Көнкүрештә кешегә чиксез булушучы иптәш булган кебек, аның илне саклау, дошман явына каршы сугышта да бер бәдән булып яуны уртаклашучы хәйран калырлык бер хәл. Атның катнашыннан башка һичбер җитди дастан юк.

Сабантуй алдыннан берничә көн элек малайлар ат аягы кыздыра башлыйлар. Нинди зур бәхет ир балага! Ул аргамакка атлана! Сабантуй гарәфәсендә сөрән салып йөрү дә - атка атланган ир балалар эше. Ярышка әзерләүче үсмер атның аркасына бер әйбер салмыйча, шәрә биленә атлана. Моның, әлбәттә, атка җиңелерәк булсын өчен дә шулай эшләнүе мөмкин. Шуның белән бергә яшүсмерне күнектерү, җан-фәрманга сикереп бара торган атның билендә егылмыйча, нык утырырга өйрәтү өчен шулай эшлиләр. Өзәңгелеияр өстендә утыруны һәркем булдыра. Тотынып нәрсә дә юк.

Җан-фәрманга чапканда тезгенгә тотынуының әһәмияте дә калмый. Ул буш булырга тиеш.

**Йомылып та атның чапкан чакта**
**Тезгәннәрен тотма, буш җибәр!**
**Андыса да дошман алдыралмас,**
**Буш җибәргән атка кош диләр.**



«Сабантуй» Рианова Гульназ

Җайдак егылса, кайвакыт ат туктый, ләкин гадәттә ярыштан чыкмый, чабуын дәвам итә. Кешесез килеп җитеп, беренчелекне алган атлар ярыштан чыгалар.

Көрәш һәм ат чабышларыннан соң инде өйләренә таралып, сыра куйганнары сыра эчеп, җырлашып утыра. Монда инде җыр белән сөйләшү, әйтеш, җыр ярышы була. Җыр ярышында хатын-кыз катнашмый калмый, бию дә булырга мөмкин. Курай, скрипка, думбра уйнап җырлаганнар, биегәннәр. Хәзер гармун өстенлек итә.

Безнең халыкның биюендә төп сыйфат – ирләрнең хәрәкәтчән, төрле виражлар ясавы, ә хатын-кызның хәрәкәтләре бик тыйнак, нәзәкәтле һәм грациоз, зифа булган. Моңа каршы бер сүз дә әйтеп булмый.

Борынгыда Сабантуйга һәм туйларга сыра кую була иде. Ләкин каты аракы түгел, йомшак сыра булган. Безнең Идел буенда игенчелек культурасы тамыр җәйгән булганлыктан, сыра кую, бал ачыту кымызга караганда күбрәк таралган. Ләкин ислам культурасы эчүчелеккә каршы каты чаралар күргән.



Приложение 1

**Халык нигезләре.**
**Сабантуй!**
**Бәйрәм барышы:**

**Алып баручы:**

Безнең лагерь янында
Шау-гөр килә киң болын
Бик зур Сабан туе була
Шау-гөр килеп ел саен.
Без бу Сабан туена
Килдек әле быел да
Уйнап, биеп, җырлап, көлеп
Болынны яңгыратырга
Күрше-тирә лагерьдән
Бик күп халык җыелган
Әйтерсең сабан туена
Күктән кеше коелган
Уйнап тора музыка
Зур болын шау - гөр килә,
Җырлыйлар да, бииләр
Төрлесе төрле көйгә.

Хәерле кич мөхтәрәм дуслар. Һәммәгезгә бәйрәмле матур ял кичләре теләп калабыз. Бәйрәмнәрегез котлы, мөбәрәк булсын!

**1 укучы:** (Безнең тирә-як)

Алсу гөлләргә күмелгән
Гүзәл гөлләрдән дә гүзәл
Безнең балачак.

**2 укучы:** (Истә калачак)

Без җырлаган дәртле җырлар
Дәртле җырлар төсле дәртле
Безнең балачак.

**3 укучы:**

Ачык һәм якты
Барыр юлларым, Татарстаным
Син – туган ягым,
Син – минем таңым
Татарстаным.

**Заманча бию.**

**4 укучы:**

Шатлыклар – куңелле бездә,
Ал кояш күгебездә.
Килегез, дуслар, кунакка
Сабантуй бүген бездә.

**5 укучы:**

Җилферди чиккән сөлгел
Бүләкләр күбебездә!
Көрәшик тә, уйнашыйк та,
Сабантуй бүген бездә.

**«Сабантуй» җыры:**

Сабан туе – хезмәт туе,
Шатлык һәм бәхет туе шул;
Уйнап, биеп, җырлап, көлеп,
Бәйрәм итик көн буе.
Шау –гөр килә киң болыннар,
Кырлар һәм су буйлары шул;
Котлы булсын колхоздашлар,
Ямьле сабан туйлары.
Бәйрәм итик шатланышып,
Туганнар, бергә -бергә шул;
Безнең бергә булуыбыз
Китсен бөтен гомергә

**Алып баручы:**

Сабантуймы, Сабантуй –
Уеннар туе бит ул,

Җиңүләр уе бит ул.
Чаптар өстендә чабып,
Катыктан тәнкә табып
Колга башына менеп
Узышларга йөгереп,
Татарча бил алышып,
Аркан белән тартышып,
Ватмый йомырка ташып,
Үткенлектә сынашып,
Җиңсәң әгәр,
Сабантуй – эчкә шатлык сыймас туй!

Ә хәзер сезнең игътибарыгызга балалар бакчасына йөрүче кызлар һәм малайлар чыгышы (балалар бииләр).

**Убырлы:** себеркесенә атланып килеп керә һәм балалрны күреп әйтә:

Нигә монда җыелдыгыз? Нәрсә булды? Нәрсә бар? Әллә аю биетәләрме?

**Алып баручы:** Бүген безнең көнебез, елга бер килә торган бәйрәм – Сабантуй! Әйдә, убырлы карчык уз, балалар белән уеннарда катнашырсың.

**Убырлы:** Ю-у-ук, нинди бәйрәм инде ул. Бүген бер бәйрәм дә булмаячак. Мин сезне еракка –урманга алып китәм. Әйдә себеркәмә утырыша торыгыз. Алып кайткач, сезне зур базга салам һәм көн саен мичемдә кыздырып ашыйм. Сез бик күп икәнсез, бер айга җитәрсез,

ашарга эзләп йөрмәсмен. Йә, ярар минем сөйләнеп торырга вакытым юк, бик ашыйсы килә, әйдәгез, утырыгыз. (себеркесен кабыза башлый)



**Алып баручы:** Балалар, нишлибез соң убырлы хәзер шатлыклы бәйрәмебезне боза бит!

**1 укучы:** Таң батырны чакырыйк.

**2 укучы:** Шүрәлене чакырыйк.

**3 укучы:** Юк, ярыш оештырыйк.

**Алып баручы:** Ярый, әйдәгез ярыш оештырыйк! Беренче ярыш шулай булсын: бик көчле итеп "Бүген бездә Сабантуй" –дип өч тапкыр кычкырырга кирәк. Бөтен шәһәр ишетсен. Кем көчлерәк кычкырыр. Убырлымы, балалармы? (кычкыралар)

**Убырлы карчык:** Ха! Күрдегезме, мин җиңдем. Утырыгыз әйдә.

**Алып баручы:** Балалар, нишлибез? Иң шәп балаларны алып китә бит бу. Әйдәгез, ярдәмгә Шүрәлене чакырыйк. (чакыралар)

**Шүрәле:** Исәнмесез,балалар! Ник чакырдыгыз?

**Алып баручы:** әйдә уз шүрәле. Менә убырлы килеп безнең бәйрәмне бозды. Җитмәсә безнең балаларны үзе белән алып китмәкче.

**Убырлы карчык:** алып китәм, барысында алып китәм, утырыгыз әйдә!

**Шүрәле:** Юк, Убырлы карчык, син минем Таң батырым белән көрәшеп кара,җиңә алсаң балалар синеке.(көрәшәләр, таң батыр җиңә)

**Алып баручы:** Балалар, өченче җаза бирергә кирәк.

**Шүрәле:** Убырлы карчык, әйдә кети- кети уйныйбыз.

**Убырлы карчык:** Ух... Мин сине хәзер сихерлим.

**Шүрәле:** Ләкин башта уйныйк.

**Убырлы карчык:** Әйдә инде бик сорагач уйныйк. Соңгы теләгең.

(шүрәле кытыклый) Шүрәле, зинһар,җитте, кытыклама! Үләм бит! Балалар, кичерегез мине, мин бүтән явыз, усал булмам, тик зинһар җибәрегез мине!

**Шүрәле:** Балалар, нишлибез, җибәрәбезме убырлыны!

**Балалар:** Җибәрәбез, кичерәбез.

**Алып баручы:** Тик бер нәрсә, син бүтән беркайчан да явыз булмассыңмы!

**Убырлы карчык:** Булмам! Мин яхшы якка төзәлергә сүз бирәм. Әйдәгез әле минем сүзләрне беркетеп бер татарча биеп алыйк.

**Барысы да татарча бииләр.**

**Таң батыр:** дусларым минем сезнең һәрберегезгә алып килгән күчтәнәчләрем бар. (Таң батыры бүләкләрне һәр отрядка бирә) Сабантуй гүзәле белән Сабантуй батырына бүләкләрем зурдан. (сабантуй гүзәле мәйдан уртасына чакырыла һәм лагерьның иң мактаулы грамотасы белән бүләкләнә) Сабантуй батырына грамотаны сезгә биреп калдырам, тапшы-

рырга онытмагыз! Хушыгыз, балалар.

**Алып баручы:** Кул чабабыз, дуслар, гүзәлләрнең гүзәленә һәм батырларның батырына дипломнар тапшырыла, уңышлар сезгә.

**Алып баручы:** Шуның белән безнең бәйрәмебезнең беренче өлеше тәмам. Ә хазер сабан туйның иң кызыклы вакыты, ярышлар. Әйдәгез, рәхим итегез. Барыгыз да күчеш планы нигезендә ярышларга барагыз. Иң күп йолдызчык җыйган укучы җиңүче дип танылачак һәм аңа грамота белән бүләк тапшырылачак. Сезнең барчагызга да уңышлар.

**Ярышлар тәртибе:**

1. көрәш;
2. чүлмәк вату;
3. аркан тартышу;
4. йомырка кабып йөгерү;
5. капчык киеп йөгерү;
6. капчык белән сугышу;
7. чокырга су ташу;
8. кул көрәше;
9. катыктан тиен эзләү;
10. бию ярышы.

**Алып баручы:** Сабантуйның иң дулкынландыргыч вакыты җитте. Балалар, барыгыз да бүген ярыштыгыз, үзегезнең көчегезне сынадыгыз һәм җиңүчеләр бүләкләр алды. Шуның белән Сабантуйны тәмамлыйбыз. Алда әле безнең бәйрәмнәребез дәвам итә. Без әле шәһәр Сабантуйларында да очрашырбыз. Бәйрәмнәребез мөбәрәк булсын. Әйдәгез Сабантуй батыры белән, Сабантуй гүзәленә лагерь эләмен төшерергә тапшырыйк.



«Борьба» из цикла «Сабантуй» Абзгильдин А.А.

# Исәнме, сабантуй!

**Алып баручы:**
Бар күңеллек бөтен дөньяда, бар,
Бер ямь бүген!
- Нәрсәдән бу? – Мин беләм: бәйрәм бүген
- Бәйрәм бүген!
Бер мөкатдәс хис белән һәрбер кеше
Хайран бүген:
Уйный сазым да минем бәйрәм көен:
- Бәйрәм бүген!
Арттыра, күрдем, кояш гадәттәгедән балкуын:
Ул киенгәндер! – дидем, бәйрәм бүген,
бәйрәм бүген!

Сабан туе татар халкының иң кадерле милли бәйрәме бу. Дуслык һәм хезмәт тантанасы. Халкыбызның рухи дөньясының, күңел байлыгын чагылдыра ул.

Сабан туе!

Кайчандыр Сабан туена яңа оек-чабата, ап=ак яңа күлмәк кию бәхетенә ирешкән малай күңелендә - вак ташлар өстендә сикерә-сикерә челтерәгән чишмә кебек – туган ул тойгы яз буе тир түгеп, үзенә дә, байга да эшләргә өлгереп, быел берничә эчминнек бодай, тары, берничә таяк бәрәңге чәчергә тапкан игенче күңелендә, вак куаклар аша кояш нурлары төшкән тар инеш төсле, якты өметләр агымы булып калыккан.

Хөрмәтле иптәшләр, кунаклар!

Барыгызны да Сабан туе  мәйданына чакырабыз.

Бәйрәмне башлыйбыз, Сабан туе мәйданына рәхим итегез!

Сабан туйга рәхим итегез!
Көн буена җырлап, уйнап,
Көч сынашып, күңел ачып,
Бер туйганчы биеп кит,
Сабан туйга рәхим ит!

**Алып баручы:**

Хөрмәтле иптәшләр, хөрмәтле ил картлары-аксакаллар, апалар, әбиләр, балалар, гүзәл кызлар, батыр егетләр, кунаклар! Халкыбызның онытылмас матур традициясенә әйләнгән Сабан туе бәйрәмен дәвам итәбез.

Сабан туе, Сабан туй-
Җин сызганып көткән туй,

Күңелне җилкеткән туй,
Көрәшеп җир селкеткән туй –
Ил көчен белгерткән туй.

**Алып баручы:**

Бүген Сабан туе – ачык ярыш, уртак бәйрәм, халык арасындагы талантлар көченә смотр.

Көчләрнең, дә көчлесе, җитезләрнең дә җитезе, батырларның да батыры гадел рәвештә билгеләнә монда. Ат чабышлары, капчык белән сугышу, капчык киеп йөгерү кебек кызыклы ярышларда барысы да – карты да, яше дә катнаша.

**Беренче конкурс «Баганага менү»**

Шул абыйлар
Әй, кызыгып карыйлар,
Багана шома булганга,
Бер дә менә алмыйлар.

**Алып баручы:**

Шунда бер җирдә тагын
Стан куйган җиргә качып
Шул станга ике абый
Утырыгыз атланып.
Кулга тотыгыз асып
Салам тутырган капчык,
Капчык белән, чиратлашып,
Бәрешегез “шап” та “шоп”.
Баганаауган төсле,
Гөрселдәп килеп төште,
Шундый каты төште, малай,
Урманны дер селкетте.



**Икенче конкурс «Капчык сугышы».**

Сөлге чигәм асыл җепләр белән,
Йөрәк хисен салып бужыырга Насыйп булса иде бу бүләгем
Мәйданарда җиңгән батырга.
Ефәк җепләр белән сөлге чиктем,
Уртасында чәчәк – гөл генә.
Җиңеп алсаң егет бу бүләкне
Вәгьдә бирәм сиңа мәңгегә.

**Өченче конкурс «Көрәш».**

Әйдәгез, яшь кызлар, уңганнар,
Киленнәр, апалар, әбиләр
Кайсыгыз уңганрак, җитезрәк
Стартка рәхим итегез

**Дүртенче конкурс**
**«Сулы чиләкләр белән йөгерү».**

Макта, макта, безнең яшьләр
Ничек җитез атлыйлар!
Биергә дә оста алар,
Эштә дә сынатмыйлар.

**Бишенче конкурс**
**«Кашыкка йомырка салып йөгерү».**

**Алып баручы:**

Сабантуй, Сабантуй
И гүзәл соң, безнең сабан туйлар!
Халкым сыман тыйнак, ягымлы,
Халкым кебек олы, киң күңелле,
Халкым кебек дәртле һәм моңлы.
Сабан туе – ул тынычлык туе,
Даны яңгырый аның җырларда,
Шушы бәйрәмнән дә күңеллерәк
Бәйрәм юктыр кебек беркайда.
Сабаннарга җиһан табыныр һаман,
Сабан туйлар булыр һәр заман,
Җир туфрагын, снярядлар түгел,
Назлый-назлый сөрсен гел Сабан!

## Библиографик исемлек.


1. Баянов, Ә. Кызыл ут / Ә. Баянов. – Шигырьләр, шигъри трагедия. – Казан : Татар. кит. нәшр.,1999. – 287 б.

2. Зәйнашева, Г. Гимназиядә дуслаштык : җырлар /Г. Зәйнашева. – Казан : Еникеева нәшрияты, 1996. – 31 б.

3. Мансуров, З. Җырларыбыз / З. Мансуров. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1989. – 542 б.

4. Сабан туе иртәгә //Ялкын. – 1995 . – № 6. – б. 3-4.

5. Сабан туе борынгыдан килә // Юлдаш. – 2001. – № 6. – б. 3.

6. Сабан туйларында – халкыбыз асылы // Казан утлары. – 1998. – № 8. – б. 175 – 184.

7. Харрас, Ә. Җәяүле буран : Шигырьләр, поэмалар / Ә. Харрас. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 382 б.

8. Хөснетдин, И. Бәхет дагасы : Җырлар китабы /И. Хөснетдин. – Казан: татар китабы, 1996. – 288 б.

9. Шагырьҗан, Л. Бożра вә Хөҗрә : Шигырьләр, поэмалар / Л. Шагырьҗан. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2002. – 368 б.

10. Әстерханда сабантуй гөрләде// Татарские новости. – 2008. – №6-7. – б. 2-3.




Составитель: Самигуллина Г.В., ведущий библиотекарь
О-СБ № 17 «Содружество»

Ответственный за выпуск: Юрлова О.Г., заведующая
О-СБ № 17 «Содружество»

Адрес библиотеки: г. Ульяновск, ул. В. Полевая, 13
Электронный адрес: cbs17@bk.ru
Телефон: 31-00-17

Тираж 100 экз.